РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ГЛАВА
УЗЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Татарстан ул., д. 8, п. Узяк, 422092
тел. (факс): (84360) 5-22-17,
E-mail: Uzk.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ҮЗӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**

Татарстан ур., 8 нчы йорт, Үзәк бистәсе, 422092
тел. (факс): (84360) 5-22-17,
E-mail: Uzk.Tul@tatar.ru

ОКПО 04311889 ОГРН 1021607154876 ИНН/КПП 1619000431/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№ 6** **«17» октября 2022 г.**

**«Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге Шармаш торак пунктында 2023 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст. , «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы «Үзәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең Шармаш торак пунктында 2023 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2022 елның 27 октябренә 14сәгать 00 минутка билгеләргә, Шармаш авыл клубы бинасында түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы Теләче районы, Шармаш авылы, Школьная ур., 43 йорт.

2. Гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге башлыгы тарафыннан тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

«Сез Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең Шармаш торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизацияләүгә чакырылган

гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 90 яше тулган гражданнардан тыш, 2023 елда 500,00 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм чараларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне чишү өчен юнәлтүгә ризамы:

- урамнарны яктырту объектларын карап тоту (электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын агымдагы ремонтлау һәм аларны карап тоту, эшләр өчен түләү);

- юлларны кардан чистарту, юл буйларында үләннәрне чаптыру (ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Школьная, Киров, Бобровка, Малая урамнарында, Шармаш авылы зиратына илтә торган юлда вак таш җәелгән юлларны ямау ремонты (сатып алу, күчереп йөртү, вак таш салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

- каптажны төзекләндерү, такта түшәмә кую (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү )?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны Үзәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Теләче муниципаль районының рәсми сайтында (http://tulachi.tatarstan.ru), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

В. Н. Котников